**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы**
**Актанышбаш авыл җирлегенең Ирмәш авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

13.03.2025 ел № 3

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлегенең Ирмәш авылындагы 2024 елның 25 декабрендәге 29 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге составына керүче Ирмәш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында.

2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлегенең Ирмәш авылындагы гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлегенең Ирмәш авылында гражданнар җыененың 2024 елның 25 декбрендәге 29 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Карарның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 90 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 50 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен __50__ граждан тавыш бирде;

«Каршы " позициясе өчен _0__ граждан тавыш бирде.

«Тыелып калдылар» позициясе өчен __0__ граждан тавыш бирде.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Актанышбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында халыкка җиткерергә.

**Актаныш муниципаль районы**
**Актанышбаш авыл җирлеге Советы рәисе** **Х.М.Хакимов**